**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Большой Битаман, ул. Московская, 2В

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ БИТАМАН**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2В

Тел./факс: +7(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**11 ноябрь 2025 г.** **№ 10**

**Олы Битаман авыл җирлеге Кече Битаман торак пунктында үзара салым кертү һәм куллану буенча гражданнар җыены уздыруны билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә Олы Битаман авыл җирлеге башлыгы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Олы Битаман авыл җирлеге Кече Битаман торак пунктында үзара салым кертү һәм аны куллану буенча 2025 елның 26 ноябрендә 18.00 сәг Кече Битаман авылы Нагорная урамы 2В йортында (авыл клубы) гражданнар җыенын уздырырырга

2. Җыенда түбәндәге сорауларны карага:

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Битаман авыл җирлегенең Кече Битаман торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтүгә ризамы:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- урамнарны яктырту җайланмаларын урнаштыру;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзекләндерүү, ремонтлау, карап тоту;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү

- чишмәне төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресу буенча рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: https://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар халыкка җиткерәгн көннән үз көченә керә

Авыл җирлеге башлыгы Д.Х.Салихов